КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 12 октябрь г.Казань № 922

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 10 октябрь, 779 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2017 ел, 10 октябрь, 779 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

түбәндәге эчтәлекле $8^1$ – $8^8$ пунктлар өстәргә:

«$8^1$. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контроле куркыныч-юнәлешле алым кулланып гамәлгә ашырыла.

Музей эше өлкәсендә дәүләт контролен оештырганда куркыныч-юнәлешле алымны куллану максатларында музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектлары

эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле алым куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары белән расланган Юридик затларның һәм индивидуаль эшмәкәрләрнең һәм (яки) алар тарафыннан кулланылла торган җитештерү объектларының эшчәнлеген куркынычның билгеле бер категориясенә яисә билгеле бер класска (куркынычлык категориясенә) кертү кагыйдәләре нигезендә хәвеф-хәтәрләрнең аерым категорияләренә кертелергә тиеш (алга таба - Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары).

Юридик затларның, шәхси эшмәкәрләрнең эшчәнлеген билгеле бер куркыныч категориясенә кертү әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә билгеләнгән критерийлар нигезендә гамәлгә ашырыла, ул мәҗбүри таләпләрне үтәмәү мөмкин булган потенциаль тискәре нәтиҗәләрнең авырлыгын, шулай ук Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына йогынты дәрәҗәсен исәпкә ала.

$8^2$. Юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата планлы тикшерүләрне планлаштыру һәм үткәрү, юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлегенә бирелгән куркыныч категориясенә бәйле рәвештә, түбәндәге периодлылык белән гамәлгә ашырыла:

сизелерлек куркыныч категориясе өчен - өч елга бер тапкыр;

уртача куркынч категориясе өчен - дүрт елга бер тапкырдан да ешрак түгел һәм биш елга кимендә бер тапкыр;

чамалы куркыныч категориясе өчен - алты елга бер тапкырдан да ешрак түгел һәм сигез елга кимендә бер тапкыр.

Эшчәнлекләре түбән куркыныч категориясенә кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшмәкәрләргә карата планлы тикшерүләр үткәрелми.

$8^3$. Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген аерым куркыныч категорияләренә кертү турындагы карар, шулай ук куркыныч категориясен үзгәртү турындагы карар Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

Юридик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр эшчәнлеген куркыныч категориясенә кертү турындагы карар булмаганда, мондый затларның эшчәнлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә түбән куркыныч категориясенә кертелгән дип санала.

Эшчәнлекләре куркыныч категорияләренең берсенә кертелгән юридик зат яисә шәхси эшмәкәр соравы буенча, Министрлык, мондый сорату кергән көннән алып 15 эш көненнән дә артмаган вакытта, аларга аларның эшчәнлекләрен куркыныч категориясенә кертү турында мәгълүмат, шулай ук аларның аларның эшчәнлекләрен куркынычның билгеле бер категориясенә керткәндә файдаланылган белешмәләр җибәрә.

$8^4$. Министрлык музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектлары исемлеген алып бара (алга таба – Исемлек). Музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектларын Исемлеккә кертү Министрлыкның музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектлары эшчәнлеген тиешле куркыныч категориясенә кертү турындагы боерыгы нигезендә гамәлгә ашырыла.

Исемлек түбәндәге мәгълүматны үз эченә ала:

1) музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектының тулы исеме;

2) музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектының төп дәүләт теркәү номеры;

3) салым түләүченең идентификацион номеры;

4) музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектының урнашу урыны;

5) музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объекты эшчәнлегенә куркыныч категориясе бирү турында Министрлык боерыгы реквизитлары, бирелгән куркыныч категориясе турында , шулай ук музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объекты эшчәнлеген билгеле бер куркыныч категориясенә кертү турында Министрлык боерыгы кабул ителгән критерийлар турында белешмәләр.

8[5]. Музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объектлары эшчәнлеген бирелгән куркыныч категориясенә кертү турында мәгълүмат Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге (алга таба – «Интернет» челтәре) рәсми сайтында (алга таба - «Интернет» челтәре) урнаштырыла һәм актуаль хәлдә саклана.

8[6]. Музей эше өлкәсендә дәүләт контроле объекты элегрәк үзенең эшчәнлегенә бирелгән куркыныч категориясен үзгәртү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары белән билгеләнгән тәртиптә Министрлыкка гариза (алга таба – гариза) бирергә хокуклы.

Гариза үз эченә түбәндәге мәгълүматларны ала:

юридик затның тулы исеме, шәхси эшмәкәрнең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булганда) ;

төп дәүләт теркәү номеры;

салым түләүченең идентификацион номеры;

юридик зат яисә шәхси эшмәкәр тарафыннан кулланыла торган җитештерү объектының урнашу урыны (җитештерү объектына куркыныч категориясе яисә куркыныч классы биргәндә);

элегрәк юридик зат яисә шәхси эшмәкәр эшчәнлегенә бирелгән куркыныч категориясе турында мәгълүмат;

юридик затның адресы, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны адресы (кирәк булганда элемтә өчен башка почта адресы), телефон һәм электрон почта адресы (булганда).

Гаризага юридик зат яисә шәхси эшмәкәр эшчәнлегенең Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына төбәк дәүләт контролен оештырганда юридик зат, шәхси эшмәкәр эшчәнлеген мөрәҗәгать итүче дәгъва кыла торган куркыныч категориясенә кертү критерийларына туры килүе турында документлар теркәлә.

Министрлык гаризаны карап тикшерә, юридик зат яисә шәхси эшмәкәр тарафыннан тапшырылган һәм аның карамагында булган документларны бәяли һәм аларны карау нәтиҗәләре буенча мондый гариза алган көннән алып 15 эш көненнән дә артмаган срокта түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

гаризаны канәгатьләндерү һәм куркыныч категориясен үзгәртү ;

гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту.

8[7]. Министрлык гаризаны карау нәтиҗәләре буенча карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә юридик затка яки шәхси эшмәкәргә гаризада күрсәтелгән почта адресы буенча тиешле хәбәрнамәне юллау юлы белән яисә вәкаләтле вазыйфаи

затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында,шәхси эшмәкәрләрнең  бердәм дәүләт реестрында булса, яисә элек алар тарафыннан дәүләт органына тапшырылган булса, юридик затның яки шәхси эшмәкәрнең электрон почтасы адресы буенча хәбәр итә.

Гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турында карар кабул иткәндә юридик затка яки шәхси эшмәкәргә баш тарту сәбәпләре турында мәгълүмат бирелергә тиеш.

Гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турында Министрлык тарафыннан кабул ителгән карар белән килешмәгән очракта, юридик зат яисә шәхси эшмәкәр мондый карарга административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.

$8^8$. Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан Россия Федерациясе Музей фондының дәүләт өлеше торышына дәүләт контролен гамәлгә ашырырга вазыйфаи регламентлар нигезендә түбәндәге түбәндәге вазыйфаи затлар вәкаләтле: 1) музей эше өлкәсендә дәүләт контроле мәсьәләләрен алып баручы Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары; 2) челтәр хезмәттәшлеге, халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек бүлеге башлыгы; 3) компетенциясенә музей эше өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашыру кергән челтәр хезмәттәшлеге, халыкара һәм төбәкара хезмәттәшлек бүлеге әйдәүче киңәшчесе.»;

күрсәтелгән Тәртипкә кушымта өстәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                      А.В.Песошин